ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ
III чакырылыш
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йортТел. 3-44-44,факс3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
III созыва
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/.3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
от 06.08.2019г

**РЕШЕНИЕ**
№39-13

**Актаныш муниципаль район Советының 2006 елның 8 февралендәге 5 номерлы карары белән расланган "Актаныш муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга һәм "Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставының 53 статьясына таянып, Актаныш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Дополнить Положение «О палате имущественных и земельных отношений Актанышского муниципального района» утвержденного решением Совета Актанышского муниципального района от 08.02.2006 №5 пунктом 8 следующего содержания:

«8. Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу

8.1. Мәнфәгатьләр каршылыгы астында оешма (учреждение) хезмәткәренең шәхси кызыксынуы аның хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәүгә йогынты ясарга мөмкин һәм шул чакта оешма (учреждение) хезмәткәренең шәхси кызыксынуы һәм үзе эшләгән оешма (учреждениенең) милкенә һәм (яки) эшлекле репутациясенә зыян китерергә сәләтле оешманың (учреждениенең) хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре арасында каршылыклар килеп чыгарга мөмкин.

8.2. Оешма (учреждение) хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәүгә тәэсир итүче яки йогынты ясарга мөмкин булган хезмәткәрнең шәхси кызыксынуы дигәндә, оешма (учреждение) хезмәткәренең акча, кыйммәтләр, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәти хокуклар яки үз-үзе өчен яки өченче затлар өчен милек характерындагы хезмәт күрсәтүләр рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге аңлана.

8.3. Оешма (палата) җитәкчесе (Рәисе) эш бирүчегә (гамәлгә куючыга) вазыйфа йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш.

8.4. Оешма (учреждение) хезмәткәре оешма (учреждение) җитәкчесенә (директорына) вазыйфа йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш. Оешма (палата) җитәкчесенә (рәисенә) хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәләрдә булган мәгълүматлар исемлеге, бу белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм хәбәрнамәләрне теркәү тәртибе оешма (палата) җитәкчесе (рәисе) тарафыннан билгеләнә.»

2. Настоящее решение обнародовать на официальном сайте Актанышского муниципального района, на портале муниципальных образований Республики Татарстан по веб-адресу http://aktanysh.tatarstan.ru и на официальном портале

правовой информации Республики Татарстан по веб-адресу http://pravo.tatarstan.ru в информационной-телекоммуникационной сети Интернет.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Муниципаль район Советы Рәисе Э.Н.Фәттахов